**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**Карары**

Илбәк авылы № 30 «02» август 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 ноябрендәге 66 нчы номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 10 октябрендәге №106 карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 мартындагы 170 номерлы «Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык карамагындагы хокук, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге 976 нчы номерлы карары белән расланган,кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында карары нигезендә

Илбәк авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 ноябрендәге 66 нчы номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибенә (2018 елның 10

октябрендәге №106 карар редакциясендә) 5.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә түбәнедәге бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«5.2. Әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында каралган шартларда төзелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә милекне арендатор тарафыннан аренда шартнамәсе буенча йөкләмәләрне үтәмәүгә бәйле яисә, әгәр арендатор әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында каралган критерийларга туры килмәсә, дәүләт милкеннән фактта файдалануның бөтен срогы аренда бәясеннән аны төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча шартнамәдә билгеләнгән 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Илбәк җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина